**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
8 июля 2021 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 3 марта 2000 года № 95 «Об Уполномоченном по правам человека в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III часть); 2010, № 6 (I часть); 2011, № 8 (I часть); 2013, № 2 (I часть); 2014, № 6 (II часть); 2015, № 6 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 41 (часть I); 2020, № 51 (часть I); 2021, № 1 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 6:
а) часть 1 после слов «не моложе 30 лет,» дополнить словами «постоянно проживающее в Российской Федерации,»;
б) часть 2 после слов «не может иметь гражданство» дополнить словом «(подданство)»;

2) в части 1 статьи 8 второе предложение исключить;

3) пункт 1 части 1 статьи 11 после слов «иметь гражданство» дополнить словом «(подданство)»;

4) в статье 12:
а) в части 1 слова «с частью 2» заменить словами «с частями 2 и 3»;
б) пункт 5 части 2 изложить в следующей редакции:
«5) прекращения гражданства Российской Федерации или приобретения гражданства (подданства) иностранного государства либо получения вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина Российской Федерации на территории иностранного государства.».

**Статья 2**

Пункт 10 части 1 статьи 15 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 25 октября 2005 года № 106-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 1; 2005, № 10 (II часть); 2006, № 12 (I часть); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2010, № 1 – 2, № 10 (II часть); 2011, № 5, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 85 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 54 (часть I), № 78 (часть I); 2020, № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 1 (часть I) изложить в следующей редакции:

«10) сообщать в письменной форме представителю нанимателя о прекращении гражданства Российской Федерации или приобретении гражданства (подданства) иностранного государства либо получении вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина на территории иностранного государства, в день, когда государственному служащему стало известно об этом, но не позднее пяти рабочих дней со дня прекращения гражданства Российской Федерации или приобретения гражданства (подданства) иностранного государства либо получения вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина на территории иностранного государства;».

**Статья 3**

Подпункт «в» пункта 1 статьи 4 Закона Республики Татарстан от 18 марта 2004 года № 15-ЗРТ «О статусе депутата Государственного Совета Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 3 (I часть); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I часть); 2011, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I часть), № 12 (II часть); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I), № 94 (часть I); 2020, № 57 (часть I); 2021, № 1 (часть I) изложить в следующей редакции:

«в) прекращения гражданства Российской Федерации или наличия гражданства (подданства) иностранного государства либо вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина Российской Федерации на территории иностранного государства;».

**Статья 4**

Пункт 4 части 2 статьи 8 Закона Республики Татарстан от 7 июня 2004 года № 37-ЗРТ «О Счетной палате Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 65-ЗРТ) (Ведомости

Государственного Совета Татарстана, 2004, № 6; 2011, № 10 (I часть); 2013, № 3; 2014, № 6 (I часть); 2016, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I); 2018, № 83 (часть I); 2019, № 19 (часть I), № 49 (часть I); 2021, № 1 (часть I) изложить в следующей редакции:

«4) прекращения гражданства Российской Федерации или наличия гражданства (подданства) иностранного государства либо вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина Российской Федерации на территории иностранного государства;».

**Статья 5**

Внести в Закон Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 7 (II часть); 2005, № 2, № 4 (I часть), № 6 (II часть), № 11; 2006, № 4, № 7 (I часть); 2007, № 7 (I часть), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (II часть); 2011, № 3, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2013, № 3, № 7, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 11 (VI часть); 2015, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2016, № 3, № 5, № 6 (I часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 27 (часть I), № 55 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 22 (часть I), № 54 (часть I), № 78 (часть I), № 92 (часть I); 2019, № 19 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 36 (часть I) следующие изменения:

1) часть 1 статьи 16 дополнить пунктом $7^1$ следующего содержания:

«$7^1$) обеспечение первичных мер пожарной безопасности в границах муниципальных районов за границами городских и сельских населенных пунктов;»;

2) часть 1 статьи $16^1$ дополнить пунктом 18 следующего содержания:

«18) создание муниципальной пожарной охраны.»;

3) часть $5^1$ статьи 26 дополнить пунктом 4 следующего содержания:

«4) обязан сообщить в письменной форме главе муниципального образования о прекращении гражданства Российской Федерации либо гражданства иностранного государства – участника международного договора Российской Федерации, в соответствии с которым иностранный гражданин имеет право быть избранным в органы местного самоуправления, или приобретении гражданства (подданства) иностранного государства либо получении вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание на территории иностранного государства гражданина Российской Федерации либо иностранного гражданина, имеющего право на основании международного договора Российской Федерации быть избранным в органы местного самоуправления, в день, когда ему стало известно об этом, но не позднее пяти рабочих дней со дня прекращения гражданства Российской Федерации либо гражданства иностранного государства или приобретения гражданства (подданства) иностранного государства либо

получения вида на жительство или иного документа, предусмотренного настоящим пунктом.».

**Статья 6**

Внести в Закон Республики Татарстан от 4 марта 2006 года № 16-ЗРТ «О государственных должностях Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 3 (I часть); 2007, № 7 (I часть); 2008, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (II часть); 2010, № 1 – 2, № 4 (I часть); 2011, № 5; 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 11 (I часть); 2016, № 4, № 6 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I); 2018, № 1 (часть I); 2020, № 37 (часть I), № 87 (часть I) следующие изменения:

1) статью 4 дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. Лицом, замещающим государственную должность Республики Татарстан, может быть гражданин Российской Федерации, не имеющий гражданства (подданства) иностранного государства либо вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина Российской Федерации на территории иностранного государства.»;

2) пункт 6 статьи 6 изложить в следующей редакции:

«6) прекращением гражданства Российской Федерации или наличием гражданства (подданства) иностранного государства либо вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина Российской Федерации на территории иностранного государства;».

**Статья 7**

Статью 5 Закона Республики Татарстан от 1 августа 2011 года № 59-ЗРТ «Об Уполномоченном по правам ребенка в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2011, № 8; 2013, № 11 (I часть); 2014, № 6 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 49 (часть I) изложить в следующей редакции:

«Статья 5. **Требования, предъявляемые к кандидату на должность Уполномоченного по правам ребенка**

На должность Уполномоченного по правам ребенка может быть назначен гражданин Российской Федерации, постоянно проживающий в Российской Федерации, не имеющий гражданства (подданства) иностранного государства либо вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина Российской Федерации на территории иностранного государства, обладающий безупречной репутацией, имеющий высшее образование и опыт работы по реализации и защите прав и законных интересов детей,

восстановлению нарушенных прав и законных интересов детей либо опыт правозащитной деятельности.».

**Статья 8**

Внести в Кодекс Республики Татарстан о муниципальной службе (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 6 (II часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 17 (часть I), № 52 (часть I), № 55 (часть I), № 94 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 54 (часть I), № 78 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 19 (часть I), № 49 (часть I); 2020, № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 57 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 1 (часть I) следующие изменения:

1) в части 1 статьи 14:

а) пункт 9 изложить в следующей редакции:

«9) сообщать в письменной форме представителю нанимателя (работодателю) о прекращении гражданства Российской Федерации либо гражданства (подданства) иностранного государства – участника международного договора Российской Федерации, в соответствии с которым иностранный гражданин имеет право находиться на муниципальной службе, в день, когда муниципальному служащему стало известно об этом, но не позднее пяти рабочих дней со дня прекращения гражданства Российской Федерации либо гражданства (подданства) иностранного государства – участника международного договора Российской Федерации, в соответствии с которым иностранный гражданин имеет право находиться на муниципальной службе;»;

б) дополнить пунктом $9^1$ следующего содержания:

«$9^1$) сообщать в письменной форме представителю нанимателя (работодателю) о приобретении гражданства (подданства) иностранного государства либо получении вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина на территории иностранного государства, в день, когда муниципальному служащему стало известно об этом, но не позднее пяти рабочих дней со дня приобретения гражданства (подданства) иностранного государства либо получения вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина на территории иностранного государства;»;

2) в части 1 статьи 15:

а) пункт 6 изложить в следующей редакции:

«6) прекращения гражданства Российской Федерации либо гражданства (подданства) иностранного государства – участника международного договора Российской Федерации, в соответствии с которым иностранный гражданин имеет право находиться на муниципальной службе;»;

б) пункт 7 изложить в следующей редакции:

«7) наличия гражданства (подданства) иностранного государства либо вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина на территории иностранного государства, если иное не предусмотрено международным договором Российской Федерации;»;

3) пункт 2 части 1 статьи 23 признать утратившим силу.

**Статья 9**

Внести в Закон Республики Татарстан от 5 июля 2013 года № 54-ЗРТ «Об Уполномоченном при Президенте Республики Татарстан по защите прав предпринимателей» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 7; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 22 (часть I) следующие изменения:

1) часть 2 статьи 5 изложить в следующей редакции:

«2. Уполномоченным может быть назначен гражданин Российской Федерации, постоянно проживающий в Российской Федерации, не имеющий гражданства (подданства) иностранного государства либо вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина Российской Федерации на территории иностранного государства, и имеющий высшее образование.»;

2) пункт 5 части 1 статьи 6 изложить в следующей редакции:

«5) прекращения гражданства Российской Федерации или наличия гражданства (подданства) иностранного государства либо вида на жительство или иного документа, подтверждающего право на постоянное проживание гражданина Российской Федерации на территории иностранного государства;».

**Статья 10**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением пунктов 1 и 2 статьи 5 настоящего Закона.

2. Пункты 1 и 2 статьи 5 настоящего Закона вступают в силу с 1 января 2022 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
16 июля 2021 года
№ 50-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:
а) 1 өлештә «30 яшьтән яшьрәк булмаган,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясендә даими яшәүче,» сүзләрен өстәргә;
б) 2 өлештә «чит дәүләт гражданлыгы» сүзләреннән соң «(подданлыгы)» сүзен өстәргә;

2) 8 статьяның 1 өлешендә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

3) 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «чит дәүләт гражданлыгын» сүзләреннән соң «(подданлыгын)» сүзен өстәргә;

4) 12 статьяда:
а) 1 өлештә «2 өлеше» сүзләрен «2 һәм 3 өлешләре» сүзләренә алмаштырырга;
б) 2 өлешнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыкса яисә чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алса йә яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ алса.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 1 өлешенең 10 пунктын (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) дәүләт хезмәткәренә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу яисә чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алу йә яшәүгә рөхсәт яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ алу турында мәгълүм булган көнне, ләкин Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан яисә чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алган йә яшәүгә рөхсәт яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ алган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яллаучы вәкиленә бу хакта язмача хәбәр итәргә;».

**3 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 пунктының «в» пунктчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыкканда яисә чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документы булганда;».

**4 статья**

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 2 өлешенең 4 пунктын (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш); 2016, № 4; Татарстан

Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан яисә чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документы булган;».

**5 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

«$7^1$) муниципаль районнар чикләрендә шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләреннән читтә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;»;

2) $16^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

«18) янгыннан саклау буенча муниципаль хезмәт булдыру.»;

3) 26 статьяның $5^1$ өлешенә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4) үзенә Россия Федерациясе гражданлыгыннан йә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгыннан чыгу яисә чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алу йә яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе гражданының йә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайлану хокукы булган чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документын алу турында мәгълүм булган көнне, ләкин Россия Федерациясе гражданлыгыннан йә чит дәүләт гражданлыгыннан чыккан яисә чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алган йә яшәүгә рөхсәт яисә әлеге пунктта каралган бүтән документ алган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлек башлыгына бу хакта язмача хәбәр итәргә тиеш.».

**6 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат булып чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документы булмаган Россия Федерациясе гражданы булырга мөмкин.»;

2) 6 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгуга яисә чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ булуга;».

**7 статья**

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8; 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатка куела торган таләпләр**

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына Россия Федерациясендә даими яшәүче, чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документы булмаган, яхшы репутациягә ия, югары белемле һәм балалар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру һәм яклау, балаларның бозылган хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу өлкәсендә эш тәҗрибәсе йә хокук яклау эшчәнлеге тәҗрибәсе булган Россия Федерациясе гражданы билгеләнеп куелырга мөмкин.».

**8 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 1 өлешендә:

а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) муниципаль хезмәткәргә Россия Федерациясе гражданлыгыннан йә чит ил гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгыннан (подданлыгыннан) чыгу турында мәгълүм булган көнне, ләкин Россия Федерациясе гражданлыгыннан йә чит ил гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгыннан (подданлыгыннан) чыккан көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) бу хакта язмача хәбәр итәргә;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

«$9^1$) муниципаль хезмәткәргә чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алу йә яшәүгә рөхсәт яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ алу турында мәгълүм булган көнне, ләкин чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алган йә яшәүгә рөхсәт яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ алган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) бу хакта язмача хәбәр итәргә;»;

2) 15 статьяның 1 өлешендә:

а) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгыннан йә чит ил гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгыннан (подданлыгыннан) чыкса;»;

б) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документы булса;»;

3) 23 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

**9 статья**

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Вәкаләтле вәкил вазыйфасына Россия Федерациясендә даими яшәүче, чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документы булмаган, югары белемле Россия Федерациясе гражданы билгеләп куелырга мөмкин.»;

2) 6 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыкса яисә чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документы булса;».

**10 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 5 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 5 статьясындагы 1 һәм 2 пунктлары 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 16 июль
№ 50-ТРЗ